**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 гыйнварындагы 14 номерлы карары**

**Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартларын һәм тәртибен раслау хакында**

2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында»гы федераль законның 4 статьясындагы 8 өлеше, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 13 сентябрендәге 1602 номерлы «Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр хакында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 7 октябрендәге 1086 номерлы «Килешүләрнең бер ягы Татарстан Республикасы булган һәм Россия Федерациясе булмаган капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү, аларга үзгәрешләр кертү, аларны гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау хакында»гы карары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Казан шәһәрендә инвестиция эшчәнлеген үстерү өчен уңай шартлар булдыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартларын һәм тәртибен (кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 гыйнварындагы
14 номерлы карары белән
расланды

## Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Шартлар һәм тәртип 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында»гы федераль законның (алга таба – 69-ФЗ номерлы закон) 4 статьясындагы 8 өлеше нигезендә эшләнде һәм капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзү шартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Килешү төзүгә, аңа үзгәрешләр кертүгә һәм аны өзүгә, шулай ук килешүләр буенча бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә карата, 69-ФЗ номерлы закон белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, гражданлык законнары кагыйдәләре кулланыла.

1.3. Әлеге Шартларда һәм тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр 69-ФЗ номерлы законның 2 статьясына туры килә.

### II. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе

2.1. Әгәр бер үк вакытта капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүнең бер ягы Татарстан Республикасы булса һәм инвестиция проекты Казан шәһәре территориясендә гамәлгә ашырылса, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге мондый килешүнең бер ягы булырга мөмкин.

2.2. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү 2030 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча төзелә.

2.3. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү 69-ФЗ номерлы законның 7 статьясы белән каралган тәртиптә «Капитал салулар» дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып төзелә.

2.4. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү 69-ФЗ номерлы законның 7 статьясы белән каралган процедураларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча хосусый проект инициативасы тәртибендә төзелә.

2.5. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү түбәндәге шартларны үз эченә алырга тиеш:

1) инвестиция проекты тасвирламасы, шул исәптән күчемсез милек объектлары һәм (яки) үзара бәйле һәм булдырылырга (төзелергә) яисә реконструкцияләнергә һәм (яки) модернизацияләнергә тиешле күчемле һәм күчемсез милек объектлары комплексы характеристикалары (параметрлары), шулай ук инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелә, башкарыла, күрсәтелә яки булдырыла торган товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә яисә интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә характеристикалар, аларның фаразланган күләме турында белешмәләр, аларга технологик һәм экологик таләпләр;

2) инвестиция проектын гамәлгә ашыру этапларына, шулай ук һәр шундый этапка карата кулланыла торган күрсәтмә:

а) инвестиция проектының тиешле этабын гамәлгә ашыру өчен кирәкле рөхсәтләр һәм килешүләр алу вакыты;

б) хокукларны, шул исәптән күчемсез милеккә хокукны дәүләт теркәвенә алу вакыты, шулай ук интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен һәм (яки) аларга тиңләштерелгән индивидуальләштерү чараларын дәүләт теркәвенә алу вакыты (кулланып булган очракта);

в) инвестиция проектын гамәлгә ашыруның тиешле этабы кысаларында булдырыла (төзелә) яки реконструкцияләнә һәм (яисә) модернизацияләнә торган объектны файдалануга тапшыру вакыты (кулланып булган очракта);

2.1) билгеләнгән күләмдә капитал салуларны гамәлгә ашыру вакыты;

2.2) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүдә билгеләнгән башка чараларны гамәлгә ашыру вакыты;

2.3) капитал салулар күләме;

2.4) 69-ФЗ номерлы законның 15 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау өчен планлаштырыла торган чыгымнар күләме һәм аларны каплауның планлаштырыла торган вакыты;

3) инвестиция проектын гамәлгә ашыруның 2.5 пунктның 2-2.2 пунктчаларында күрсәтелгән параметрларыннан түбәндәге чикләрдә рөхсәт ителгән иң чик тайпылышлар турында белешмәләр:

а) 25 процент – әгәр капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү хосусый проект инициативасы тәртибендә төзелгән булса, 2.5 пунктның

2.1 пунктчасында күрсәтелгән очракта (шул ук вакытта проектны гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан капитал салулар күләме 69-ФЗ номерлы законның 9 статьясындагы 4 өлеше белән каралган күләмнәрдән кимрәк була алмый);

б) 40 процент – 2.5 пунктның 2 пунктчасындагы «а – в» пунктчаларында һәм 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракларда (рөхсәт ителгән иң чик тайпылышлар күрсәткечләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан гамәлгә кертелгән тәртип нигезендә билгеләнә);

4) 69-ФЗ номерлы законның 10 статьясындагы 10 һәм 11 өлешләре белән билгеләнгән вакыт чикләрендә стабильләштерү төзәтмәләрен куллану срогы;

5) 69-ФЗ номерлы законның 14 статьясындагы 1 өлешнең 1 пунктында күрсәтелгән үзара бәйле шартнамәләр шартлары, шул исәптән субсидияләр, бюджет инвестицияләре бирү вакыты һәм күләмнәре һәм (яки) 69-ФЗ номерлы законның 14 статьясындагы 1 өлешнең 2 пунктында күрсәтелгән кредит шартнамәсе буенча процент ставкасы (аны билгеләү тәртибе), шулай ук 69-ФЗ номерлы законның 14 статьясындагы 3 өлешнең 2 пунктында күрсәтелгән субсидияләр бирү вакыты һәм күләмнәре;

6) инвестиция проектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә (Россия Федерациясе проектны гамәлгә ашыра торган оешманың зыянны каплау буенча бурычын үз өстенә алган очрактан тыш) гавами-хокукый берәмлекнең (гавами-хокукый берәмлекләрнең) проектны гамәлгә ашыра торган оешма файдасына, капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү яклары булган гавами-хокукый берәмлекләрнең тиешле бюджетларына түләү өчен, проектны гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан исәпләп чыгарылган мәҗбүри түләүләр күләменнән артмаган күләмдә түләүләр башкару (чыгымнарны каплауны тәэмин итү), аерым алганда, оешмалар табышына салымны, оешмалар милкенә салымны, өстәлгән бәягә салымны (проектны гамәлгә ашыра торган оешмага кайтарылган салымнан тыш), җир салымын (муниципаль берәмлек капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү ягы булган һәм мондый килешү белән проектны гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан җирле бюджетка түләү өчен исәпләнгән җир салымы чикләрендә 69-ФЗ номерлы законның 15 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән чыгымнарны каплау мөмкинлеге каралган очракта), чит илләрдән кертелүче товарларга таможня пошлиналарын түләү йөкләмәсенә күрсәтмә:

а) 69-ФЗ номерлы законның 12 статьясы белән каралган тәртип нигезендә, шул исәптән 69-ФЗ номерлы законның 14 статьясындагы 3 өлеше белән каралган очракларда чынбарлыктагы зыянны каплауга;

б) 69-ФЗ номерлы законның 15 статьясы белән каралган тотылган чыгымнарны каплауга (гавами-хокукый берәмлек тарафыннан мондый чыгымнарны каплау турында карар кабул ителгән очракта);

7) мониторинг тәртибе, шул исәптән проектны гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан инвестиция проектын башкару этаплары турында мәгълүмат тапшыру;

7.1) проектны гамәлгә ашыра торган оешманың капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзегән көннән алып өч ел эчендә салым мониторингы рәвешендә салым контроленә күчү буенча йөкләмәсе;

8) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү яклары арасындагы бәхәсләрне хәл итү тәртибе;

9) 69-ФЗ номерлы закон һәм капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган типлаштырылган формасы белән каралган башка шартлар.

2.6. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү, әгәр мондый килешү Россия икътисадының бер өлкәсендә яңа инвестиция проектын гамәлгә ашыруны күздә тотса, инвестиция проектын гамәлгә ашыра торган оешма белән төзелә. Бу очракта түбәндәге эшчәнлек өлкәләре һәм төрләре каралмый:

1) уен бизнесы;

2) составларында тәмәке булган продуктлар, алкоголь продукциясе, сыек ягулык җитештерү (чикләү күмердән алынган сыек ягулыкка, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә нефть чималын икенчел эшкәртү җайланмаларына карата кулланылмый);

3) эшкәртелмәгән нефть һәм табигый газ, шул исәптән нефтьнең иярчен газларын чыгару (чикләү табигый газны сыекландыру буенча инвестиция проектларына карата кулланылмый);

4) күпләп һәм ваклап сату;

5) Россия Федерациясе Үзәк банкы күзәтүендәге финанс оешмалары эшчәнлеге (чикләү инвестиция проектын финанслау максатларында кыйммәтле кәгазьләр чыгару очракларына карата кулланылмый);

6) административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) булдыру (төзү) яки реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү (аэровокзаллардан (терминаллардан), шулай ук күпфатирлы йортлардан, торак йортлардан кала [мондый йортларны территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә нигезендә төзүдән тыш]).

2.7. Хосусый инициатива тәртибендә килешү төзү өчен мөрәҗәгать итүче «Капитал салулар» дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша, 69-ФЗ номерлы законның 7 статьясындагы 6, 7 өлешләрендә күрсәтелгән документларны һәм материалларны теркәп, гариза җибәрә.

2.8. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты (алга таба – Комитет) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны карап тикшерә һәм документлар кергән көннән алып 5 эш көне эчендә Казан шәһәре Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнарына капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзү мөмкин булу яки булмау хакында бәяләмә бирү турында мөрәҗәгатьләр юллый.

Шул ук вакытта 69-ФЗ номерлы законның 7 статьясындагы 9.1 өлеше нигезендә мөрәҗәгать итүче, капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзегәнче яки капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында аның белән килешү төзүне кире какканчы, түбәндәгеләргә хокуклы:

а) гаризаны кире алу турында хәбәрнамә юллау яки мондый хәбәрнамәне «Капитал салулар» дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрү юлы белән гаризаны һәм аңа теркәлә торган докуметларны кире алырга;

б) гаризага һәм аңа теркәлә торган, 69-ФЗ номерлы законның 7 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән документларга үзгәрешләр кертергә. Бу очракта гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны карап тикшерү вакыты 30 эш көненнән дә артыграк булмаган срокка озайтыла.

2.9. Казан шәһәре Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнары 5 эш көне эчендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзү мөмкин булу яки булмау турында бәяләмә әзерлиләр һәм Комитетка юллыйлар.

2.10. Комитет, Казан шәһәре Башкарма комитетының тармак (функциональ) органнарыннан мәгълүмат алынганнан соң, 5 эш көне эчендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзү мөмкин булу яки булмау хакында Казан шәһәре Башкарма комитеты бәяләмәсен әзерли.

Документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүче белән капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзүне кире кагу өчен 69-ФЗ номерлы законның 7 статьясындагы 14 өлешендә күрсәтелгән шартлар ачыкланган очракта, Казан шәһәре Башкарма комитеты бәяләмәсендә әлеге шарт (нигезләү) күрсәтелә.

2.11. Казан шәһәре Башкарма комитетының капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзү мөмкин булу яки булмау хакындагы

бәяләмәсе, 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгына килештерү өчен җибәрелә.

2.12. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү төзү хакындагы карар Казан шәһәре Башкарма комитеты карары формасында 10 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә кабул ителә.

2.13. Гавами-хокукый берәмлекнең аерым актларын (карарларын) куллану үзенчәлекләре (стабильләштерү төзәтмәләре) проектны гамәлгә ашыра торган оешмага карата 69-ФЗ номерлы законның 9 статьясы нигезендә кулланыла.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү шартларын бозган өчен җаваплылык хакында нигезләмәләр 69-ФЗ номерлы законның 12 статьясы белән билгеләнгән.

3.2. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешү буенча бәхәсләрне карап тикшерү тәртибе 69-ФЗ номерлы законның 13 статьясы белән билгеләнгән.

3.3. Үзара бәйле шартнамәләргә кагылышлы нигезләмәләр 69-ФЗ номерлы законның 14 статьясы белән билгеләнгән.